СОВЕТ КИЛЬДЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ КИЛДИ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ — КАРАР

22.10.2019 — с. Кильдеево — 59-287

Дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруда
аерым нотариаль гамәлләр кылу турында

"Нотариат турында Россия Федерациясе законнары нигезләренә үзгәрешләр кертү хакында" 2019 елның 26 июлендәге №226-ФЗ Федераль закон нигезендә һәм "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" Федераль законның 16.1 статьясына, “Нотариат турында Россия Федерациясе законнары нигезләренә үзгәрешләр кертү хакында" (Россия Федерациясе ВС тарафыннан расланган 11.02.1993 N 4462-1) 2008 елның 15 гыйнварыннан җирлекләрнең җирле Администрация Башлыклары (Башкарма комитет җитәкчеләре) һәм нотариус җирлектә булмаган очракта, җирлекләрнең җирле үзидарәләренең махсус вәкаләтле вазыйфаи затлары түбәндәге нотариаль гамәлләр кылырга хокуклы:

1) көчемсез милек белән эш итүгә ышанычнамәләреннән тыш, ышаныч кәгазен расларга;

2) мирас мөлкәте исемлеген җитештерү юлы белән мирас мөлкәтен саклау буенча чаралар күрергә;

3) документларның күчермәләренең һәм алардан өземтәләрнең тугрылыгын раслау;

4) документларда имзаның чынлыгын дәлилләү;

5) Россия Федерациясе законнарында каралган очракларда затлар турында белешмәләрне таныклыйлар;

6) гражданның исән булу фактын таныклыйлар;

7) тиешле җирлек яки муниципаль район территориясендә яшәүче күрү буенча инвалидның үз кулы белән имзасын факсималь күрсәтеп, тәңгәллеген расларга;

8) билгеләнгән урында гражданның урнашу фактын таныклыйлар;

9) фотода сурәтләнгән зат белән гражданинның тәңгәллеген таныклыйлар;

10) документлар тапшыру вакытын таныклыйлар;

11) документның кәгазьдә урнаштырылган тигезлеген раслыйлар;

12) документның кәгазьдә электрон документка тигезлеген таныклыйлар. Килди авыл җирлегендә нотариус булмау сәбәпле, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге №131-ФЗ Федераль законның 14.1 статьясындагы 1 өлешенең 3 пункты, 20 статьясындагы 4.1 өлеше, нотариат турында Россия Федерациясе законнары нигезләренең 1 һәм 37 статьялары нигезендә

Югары Ослан муниципаль районы
Килди авыл җирлеге Советы
карар итте:

1. Югары Ослан муниципаль районының Килди авыл җирлеге җирле үзидарә органнары аерым нотариаль гамәлләр кылу буенча дәүләт вәкаләтләрен 2008 елның 15 гыйнварыннан башкаруда катнашалар дип билгеләргә кирәк.

2. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Килди авыл җирлеге Башлыгы В.М.Бурдинны нотариаль гамәлләр кылуга махсус вәкаләтле вазыйфаи зат итеп билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Килди авыл җирлеге Башкарма комитетына аерым нотариаль гамәлләр башкару вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны тәэмин итүче чаралар күрергә.

4. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Килди авыл җирлеге Советының «Аерым нотариаль гамәлләр кылу буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруда катнашу турында" 24 март 2008 ел № 25-158 карары үз көчен югалткан дип санарга.

Совет Рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы
Килди авыл җирлеге Башлыгы

В.М.Бурдин